ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.09.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**2340**

Татарстан Республикасы Башкарма комитетының «Субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында икътисади үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасында икътисади үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 - 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекны үстерү» ярдәмче программасы, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 декабрендәге 3799 номерлы карары белән расланган, «2016-2018 елларга «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлекка ярдәм итү» программасы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Башкарма комитетының «Субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы карарына, Субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибенең 7.3 пунктындагы «в» пунктчасын «эшмәкәрлек субьектларына финанс арендасына (лизинг) милек бирү өлкәсендә өч елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе булу яки соңгы хисап датасына устав капиталының зурлыгы – 2 млн сумнан да ким булмавы» яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru ) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары С.В.Кадыйровага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин